**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об автомобильных дорогах и о дорожной деятельности на территории Республики Татарстан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
14 февраля 2019 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 3 августа 2009 года № 43-ЗРТ «Об автомобильных дорогах и о дорожной деятельности на территории Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 7 – 8 (III часть); 2011, № 4 (I часть); 2012, № 1; 2013, № 4 (I часть); 2015, № 4, № 10 (I часть); 2016, № 5; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 25 (часть I); 2018, № 22 (часть I), № 29 (часть I) следующие изменения:

1) абзац четвертый статьи 1 изложить в следующей редакции:
«содействие внедрению перспективных технологий в области дорожной деятельности, а также применению национальных стандартов Российской Федерации в указанной области;»;

2) часть 3 статьи 15 после слова «строительство,» дополнить словами «непосредственно или через многофункциональный центр предоставления государственных и муниципальных услуг»;

3) в части 1 статьи 18 слова «и в местах, указанных владельцами автомобильных дорог,» исключить;

4) в статье 19:
а) часть 2 изложить в следующей редакции:

«2. Владельцы инфраструктуры железнодорожного транспорта общего пользования и владельцы железнодорожных путей необщего пользования обязаны оборудовать железнодорожные переезды устройствами, предназначенными для обеспечения безопасности движения железнодорожного транспорта, а также транспортных средств и других участников дорожного движения, содержать участки автомобильных дорог, расположенные в границах железнодорожных переездов (до шлагбаума или при отсутствии шлагбаума на расстоянии десяти метров от ближайшего рельса по пути следования транспортного средства), в соответствии с требованиями, установленными законодательством Российской Федерации о железнодорожном транспорте.»;

б) в части 3 слова «владельцев железнодорожных путей» заменить словами «владельцев инфраструктуры железнодорожного транспорта общего пользования и владельцев железнодорожных путей необщего пользования»;

в) дополнить частью 4 следующего содержания:

«4. Владельцы инфраструктуры железнодорожного транспорта общего пользования обязаны оборудовать железнодорожные переезды, расположенные на железнодорожных путях общего пользования, работающими в автоматическом режиме специальными техническими средствами, имеющими функции фото- и киносъемки, видеозаписи, для фиксации нарушений правил проезда через железнодорожные переезды. Оборудование железнодорожных переездов, расположенных на железнодорожных путях общего пользования, работающими в автоматическом режиме специальными техническими средствами, имеющими функции фото- и киносъемки, видеозаписи, обеспечение обслуживания указанных специальных технических средств, а также передача информации о выявленных с помощью указанных специальных технических средств нарушениях правил проезда через железнодорожные переезды в органы государственного контроля (надзора) осуществляются в порядке, установленном Правительством Российской Федерации.»;

5) в статье 26:

а) в части 2 слово «границ» исключить;

б) в абзаце первом части 3 слово «границ» исключить;

в) в части 4 слово «границ» исключить;

г) часть 5 признать утратившей силу;

д) в части $7^1$ слова «частью 7» заменить словами «частью 7 или $7^2$»;

е) дополнить частью $7^2$ следующего содержания:

«$7^2$. В случае, если для размещения объекта капитального строительства требуется подготовка документации по планировке территории, документация по планировке территории, предусматривающая размещение такого объекта в границах придорожной полосы автомобильной дороги, до ее утверждения согласовывается с владельцем автомобильной дороги. Это согласие должно содержать технические требования и условия, подлежащие обязательному исполнению. При этом

получение согласия на строительство, реконструкцию объекта в границах придорожной полосы автомобильной дороги в соответствии с частью 7 настоящей статьи не требуется.»;

ж) дополнить частью $7^3$ следующего содержания:

«$7^3$. Уведомление о согласии на строительство, реконструкцию предусмотренного частью 7 настоящей статьи объекта в границах придорожной полосы автомобильной дороги с документацией по планировке территории, предусматривающей размещение объекта капитального строительства в границах придорожной полосы автомобильной дороги, или об отказе в согласовании строительства, реконструкции такого объекта, документации по планировке территории направляется владельцем автомобильной дороги лицу, обратившемуся с заявлением о предоставлении согласия на строительство, реконструкцию такого объекта в границах придорожной полосы автомобильной дороги или о согласовании документации по планировке территории, предусматривающей размещение объекта капитального строительства в границах придорожной полосы автомобильной дороги, в течение тридцати дней со дня поступления указанного заявления. В уведомлении об отказе в согласовании строительства, реконструкции такого объекта, документации по планировке территории должны быть указаны все причины такого отказа.»;

з) дополнить частью $7^4$ следующего содержания:

«$7^4$. Отказ в согласовании строительства, реконструкции предусмотренного частью 7 настоящей статьи объекта в границах придорожных полос автомобильных дорог, документации по планировке территории, предусматривающей размещение объекта капитального строительства в границах придорожных полос автомобильных дорог, допускается по основаниям, установленным частью $8^4$ статьи 26 Федерального закона.»;

6) статью 31 изложить в следующей редакции:

«Статья 31. **Финансирование затрат, связанных с проектированием, строительством, реконструкцией, капитальным ремонтом, ремонтом и содержанием частных автомобильных дорог**

1. Проектирование, строительство частных автомобильных дорог осуществляются за счет средств застройщиков и иных не запрещенных законодательством Российской Федерации источников.

2. Реконструкция, капитальный ремонт, ремонт и содержание частных автомобильных дорог осуществляются за счет средств их владельцев и иных не запрещенных законодательством Российской Федерации источников.»;

7) статью 32 дополнить абзацем следующего содержания:

«публичным партнером в случае, если соглашение о государственно-частном партнерстве, соглашение о муниципально-частном партнерстве заключены в отношении частной автомобильной дороги.»;

8) в статье 33:

а) часть 3 изложить в следующей редакции:

«3. Правила оказания услуг по организации проезда транспортных средств по платным автомобильным дорогам общего пользования регионального, местного значения, платным участкам таких автомобильных дорог утверждаются соответственно Кабинетом Министров Республики Татарстан, органами местного самоуправления.»;

б) дополнить частью $3^1$ следующего содержания:

«$3^1$. Методика расчета платы за проезд транспортных средств по платным автомобильным дорогам общего пользования регионального, местного значения, платным участкам таких автомобильных дорог (в том числе если платным участком автомобильной дороги является отдельное искусственное дорожное сооружение), за исключением созданных и (или) реконструированных на основании концессионных соглашений платных автомобильных дорог общего пользования регионального, местного значения, платных участков таких автомобильных дорог (в том числе если платным участком автомобильной дороги является отдельное искусственное дорожное сооружение), утверждается соответственно Кабинетом Министров Республики Татарстан, органом местного самоуправления.»;

в) дополнить частью $3^2$ следующего содержания:

«$3^2$. Максимальный размер платы за проезд транспортных средств по платным автомобильным дорогам общего пользования регионального, местного значения, платным участкам таких автомобильных дорог (в том числе если платным участком автомобильной дороги является отдельное искусственное дорожное сооружение), за исключением созданных и (или) реконструированных на основании концессионных соглашений платных автомобильных дорог общего пользования регионального, местного значения, платных участков таких автомобильных дорог (в том числе если платным участком автомобильной дороги является отдельное искусственное дорожное сооружение), устанавливается соответственно Кабинетом Министров Республики Татарстан, органом местного самоуправления.»;

г) дополнить частью $3^3$ следующего содержания:

«$3^3$. Максимальный размер платы за проезд транспортных средств по платным автомобильным дорогам общего пользования регионального, местного значения, платным участкам таких автомобильных дорог (в том числе если платным участком автомобильной дороги является отдельное искусственное дорожное сооружение), созданным и (или) реконструированным на основании концессионных соглашений, определяется решением о заключении концессионного соглашения, принимаемым в порядке, установленном законодательством о концессионных соглашениях, и не

может превышать предельное значение, установленное соответственно Кабинетом Министров Республики Татарстан, органом местного самоуправления.»;

9) статью 34 изложить в следующей редакции:

«Статья 34. **Строительство, реконструкция и использование платных автомобильных дорог и автомобильных дорог, содержащих платные участки, на основании концессионных соглашений, соглашений о государственно-частном партнерстве, соглашений о муниципально-частном партнерстве**

1. Строительство, реконструкция и использование платных автомобильных дорог или автомобильных дорог, содержащих платные участки, могут осуществляться на основе концессионных соглашений в соответствии с Федеральным законом и законодательством о концессионных соглашениях, а также соглашений о государственно-частном партнерстве, соглашений о муниципально-частном партнерстве в соответствии с Федеральным законом и законодательством о государственно-частном партнерстве, муниципально-частном партнерстве.

2. Условие концессионного соглашения, соглашения о государственно-частном партнерстве, соглашения о муниципально-частном партнерстве, устанавливающее максимальный размер платы за проезд транспортных средств по платной автомобильной дороге или платному участку автомобильной дороги, не может быть изменено, за исключением случаев, если в течение срока действия концессионного соглашения, соглашения о государственно-частном партнерстве, соглашения о муниципально-частном партнерстве законодательством Российской Федерации, законодательством Республики Татарстан, нормативными правовыми актами органов местного самоуправления устанавливаются нормы, ухудшающие положение концессионера таким образом, что он в значительной степени лишается того, на что был вправе рассчитывать при заключении концессионного соглашения, соглашения о государственно-частном партнерстве, соглашения о муниципально-частном партнерстве.

3. В случаях, предусмотренных частью 2 настоящей статьи, условие концессионного соглашения, соглашения о государственно-частном партнерстве, соглашения о муниципально-частном партнерстве, устанавливающее максимальный размер платы за проезд транспортных средств по платной автомобильной дороге или платному участку автомобильной дороги, может быть изменено по соглашению сторон концессионного соглашения, соглашения о государственно-частном партнерстве, соглашения о муниципально-частном партнерстве на основании решения:

1) Кабинета Министров Республики Татарстан, если концедентом, публичным партнером является Республика Татарстан;

2) органа местного самоуправления, если концедентом, публичным партнером является муниципальное образование.

4. Концедентом, публичным партнером от имени Республики Татарстан выступает уполномоченный орган, если иное не предусмотрено законодательством.»;

10) в части 2 статьи 35 слово «законом» заменить словом «законодательством».

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования, за исключением пункта 4 статьи 1 настоящего Закона.

2. Пункт 4 статьи 1 настоящего Закона вступает в силу с 28 марта 2019 года.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
01 марта 2019 года
№ 14-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 14 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«юл эшчәнлеге өлкәсендә перспектив технологияләрне кертүгә, шулай ук әлеге тармакта Россия Федерациясе илкүләм стандартларын куллануга ярдәм итү;»;

2) 15 статьяның 3 өлешендә «органына» сүзеннән соң «турыдан-туры яисә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша» сүзләрен өстәргә;

3) 18 статьяның 1 өлешендә «һәм автомобиль юллары хуҗалары күрсәткән урыннарда» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 19 статьяда:
а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Гомуми файдаланудагы тимер юл транспорты инфраструктурасы хуҗалары һәм гомуми файдалануда булмаган тимер юллар хуҗалары тимер юл транспорты турындагы Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләр нигезендә тимер юл аша чыгу урыннарын тимер юл транспорты, шулай ук транспорт чаралары һәм юл хәрәкәтендә башка катнашучылар иминлеген тәэмин

итү өчен билгеләнгән җайланмалар белән җиһазларга, тимер юл аша чыгу урыннары чикләрендә урнашкан автомобиль юллары участокларын (шлагбаумга кадәр яисә, шлагбаум булмаганда, транспорт чарасы хәрәкәт итү юлы буенча иң якын рельстан ун метр арада) карап тотарга тиеш.»;

б) 3 өлештә «тимер юллар хуҗаларыннан» сүзләрен «гомуми файдаланудагы тимер юл транспорты инфраструктурасы хуҗаларыннан һәм гомуми файдалануда булмаган тимер юллар хуҗаларыннан» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

«4. Гомуми файдаланудагы тимер юл транспорты инфраструктурасы хуҗалары гомуми файдаланудагы тимер юлларда урнашкан тимер юл аша чыгу урыннарын аларны узу кагыйдәләрен бозуны теркәү өчен фотога һәм кинога төшерү, видеога яздыру функцияләре булган автомат режимда эшләүче махсус техник чаралар белән җиһазларга тиеш. Гомуми файдаланудагы тимер юлларда урнашкан тимер юл аша чыгу урыннарын фотога һәм кинога төшерү, видеога яздыру функцияләре булган автомат режимда эшләүче махсус техник чаралар белән җиһазлау, әлеге махсус техник чараларга хезмәт күрсәтүне тәэмин итү, шулай ук күрсәтелгән махсус техник чаралар ярдәмендә ачыкланган тимер юл аша чыгу урыннарын узу кагыйдәләрен бозу турындагы мәгълүматны дәүләт тикшереп торуы (күзәтчелеге) органнарына тапшыру Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

5) 26 статьяда:

а) 2 өлештә «полосалары чикләрен» сүзләрен «полосаларын» сүзенә, «полосаларының чикләрен» сүзләрен «полосаларын» сүзенә алмаштырырга;

б) 3 өлешнең беренче абзацында «полосалары чикләрен» сүзләрен «полосаларын» сүзенә, «полосаларының чикләрен» сүзләрен «полосаларын» сүзенә алмаштырырга;

в) 4 өлештә «полосалары чикләрен» сүзләрен «полосаларын» сүзенә, «полосаларының чикләрен» сүзләрен «полосаларын» сүзенә алмаштырырга;

г) 5 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

д) $7^1$ өлештә «7 өлешендә» сүзләрен «7 яисә $7^2$ өлешендә» сүзләренә алмаштырырга;

е) түбәндәге эчтәлекле $7^2$ өлеш өстәргә:

«$7^2$. Капиталь төзелеш объектын урнаштыру өчен территорияне планлаштыру документларын әзерләү таләп ителгән очракта, мондый объектны автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә урнаштыру күздә тотылган территорияне планлаштыру документлары раслanганчы, алар автомобиль юлының хуҗасы белән килештерелә. Бу ризалыкта мәҗбүри үтәлергә тиешле техник таләпләр һәм шартлар күрсәтелергә тиеш. Автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә объектны төзүгә, реконструкцияләүгә әлеге статьяның 7 өлеше нигезендә ризалык алу таләп ителми.»;

ж) түбәндәге эчтәлекле $7^3$ өлеш өстәргә:

«$7^3$. Капиталь төзелеш объектын автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә урнаштыру күздә тотылган территорияне планлаштыру документлары

белән автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә әлеге статьяның 7 өлешендә каралган объектны төзүгә, реконструкцияләүгә ризалык бирү турында яисә мондый объектны төзүне, реконструкцияләүне, территорияне планлаштыру документларын килештерүдән баш тарту хакында хәбәрнамә автомобиль юлының хуҗасы тарафыннан шундый объектны автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә төзүгә, реконструкцияләүгә ризалык бирү турында яисә капиталь төзелеш объектын автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә урнаштыру күздә тотылган территорияне планлаштыру документларын килештерү хакында гариза белән мөрәҗәгать иткән затка әлеге гариза кергән көннән алып утыз көн эчендә җибәрелә. Мондый объектны төзүне, реконструкцияләүне, территорияне планлаштыру документларын килештерүдән баш тарту турындагы хәбәрнамәдә мондый баш тартуның барлык сәбәпләре дә күрсәтелергә тиеш.»;

з) түбәндәге эчтәлекле $7^4$ өлеш өстәргә:

«$7^4$. Автомобиль юлларының юл буе полосалары чикләрендә әлеге статьяның 7 өлешендә каралган объектны төзүне, реконструкцияләүне, капиталь төзелеш объектын автомобиль юлларының юл буе полосалары чикләрендә урнаштыру күздә тотылган территорияне планлаштыру документларын килештерүдән баш тарту Федераль законның 26 статьясындагы $8^4$ өлешендә билгеләнгән нигезләрдә рөхсәт ителә.»;

6) 31 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«31 статья. **Хосусый автомобиль юлларын проектлауга, төзүгә, реконструкцияләүгә, капиталь ремонтлауга, ремонтлауга һәм карап тотуга бәйле чыгымнарны финанслау**

1. Хосусый автомобиль юлларын проектлау, төзү төзүчеләр акчалары һәм Россия Федерациясе законнарында тыелмаган башка чыганаклар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2. Хосусый автомобиль юлларын реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту аларның хуҗалары акчалары һәм Россия Федерациясе законнарында тыелмаган бүтән чыганаклар исәбеннән гамәлгә ашырыла.»;

7) 32 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү, муниципаль-хосусый партнерлык хакында килешү хосусый автомобиль юлына карата төзелгән очракта, гавами партнер тарафыннан.»;

8) 33 статьяда:

а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Региональ, җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы түләүле автомобиль юллары, мондый автомобиль юлларының түләүле участоклары буйлап транспорт чаралары йөрүне оештыру буенча хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләре тиешенчә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле үзидарә органнары тарафыннан раслана.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:

«$3^1$. Транспорт чаралары региональ, җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы түләүле автомобиль юлларыннан, мондый автомобиль юлларының түләүле участокларыннан (шул исәптән автомобиль юлының түләүле участогы аерым ясалма юл корылмасыннан гыйбарәт булса да) йөргән өчен түләүне исәпләү методикасы, концессия килешүләре нигезендә төзелгән һәм (яисә) реконструкцияләнгән региональ, җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы түләүле автомобиль юлларыннан, мондый автомобиль юлларының түләүле участокларыннан (шул исәптән автомобиль юлының түләүле участогы аерым ясалма юл корылмасыннан гыйбарәт булса да) тыш, тиешенчә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле үзидарә органы тарафыннан раслана.»;

в) түбәндәге эчтәлекле $3^2$ өлеш өстәргә:

«$3^2$. Транспорт чаралары региональ, җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы түләүле автомобиль юлларыннан, мондый автомобиль юлларының түләүле участокларыннан (шул исәптән автомобиль юлының түләүле участогы аерым ясалма юл корылмасыннан гыйбарәт булса да) йөргән өчен түләүнең максималь күләме, концессия килешүләре нигезендә төзелгән һәм (яисә) реконструкцияләнгән региональ, җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы түләүле автомобиль юлларыннан, мондый автомобиль юлларының түләүле участокларыннан (шул исәптән автомобиль юлының түләүле участогы аерым ясалма юл корылмасыннан гыйбарәт булса да) тыш, тиешенчә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле үзидарә органы тарафыннан раслана.»;

г) түбәндәге эчтәлекле $3^3$ өлеш өстәргә:

«$3^3$. Транспорт чаралары концессия килешүләре нигезендә төзелгән һәм (яисә) реконструкцияләнгән региональ, җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы түләүле автомобиль юлларыннан, мондый автомобиль юлларының түләүле участокларыннан (шул исәптән автомобиль юлының түләүле участогы аерым ясалма юл корылмасыннан гыйбарәт булса да) йөргән өчен түләүнең максималь күләме концессия килешүләре турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә кабул ителә торган концессия килешүе төзү хакында карар белән билгеләнә һәм тиешенчә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнгән иң чик күләмнән артык була алмый.»;

9) 34 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«34 статья. **Концессия килешүләре, дәүләти-хосусый партнерлык турында килешүләр, муниципаль-хосусый партнерлык хакында килешүләр нигезендә түләүле автомобиль юлларын һәм түләүле участоклары булган автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү һәм алардан файдалану**

1. Түләүле автомобиль юлларын яисә түләүле участоклары булган автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү һәм алардан файдалану, Федераль законга һәм концессия килешүләре турындагы законнарга таянып, концессия килешүләре, шулай ук, Федераль законга һәм дәүләти-хосусый партнерлык,

муниципаль-хосусый партнерлык хакындагы законнарга таянып, дәүләти-хосусый партнерлык турында килешүләр, муниципаль-хосусый партнерлык хакында килешүләр нигезендә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

2. Транспорт чаралары түләүле автомобиль юлыннан яисә автомобиль юлының түләүле участогыннан йөргән өчен түләүнең максималь күләмен билгели торган концессия килешүенең, дәүләти-хосусый партнерлык турында килешүнең, муниципаль-хосусый партнерлык хакында килешүнең шарты үзгәртелә алмый, моңа концессия килешүенең, дәүләти-хосусый партнерлык турында килешүнең, муниципаль-хосусый партнерлык хакында килешүнең гамәлдә булу срогы дәвамында Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән концессионерның хәлен концессия килешүе, дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү, муниципаль-хосусый партнерлык хакында килешү төзегән вакытта ул исәп тотканнан сизелерлек дәрәҗәдә мәхрүм итү юлы белән начарайта торган нормалар билгеләнү очраклары керми.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендә каралган очракларда, транспорт чаралары түләүле автомобиль юлыннан яисә автомобиль юлының түләүле участогыннан йөргән өчен түләүнең максималь күләмен билгели торган концессия килешүенең, дәүләти-хосусый партнерлык турында килешүнең, муниципаль-хосусый партнерлык хакында килешүнең шарты концессия килешүе, дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү, муниципаль-хосусый партнерлык хакында килешү якларының үзара ризалыгы белән түбәндәгеләрнең карары нигезендә үзгәртелергә мөмкин:

1) концедент, гавами партнер Татарстан Республикасы булса, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты;

2) концедент, гавами партнер муниципаль берәмлек булса, җирле үзидарә органы.

4. Законнарда башкасы каралмаган булса, Татарстан Республикасы исеменнән концедент, гавами партнер буларак вәкаләтле орган эш йөртә.»;

10) 35 статьяның 2 өлешендә «закон белән» сүзләрен «законнарда» сүзенә алмаштырырга.

**Статья 2**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пункты 2019 елның 28 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 01 март
№ 14-ТРЗ